ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 февраль 2022ел № 750

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Күмү һәм җирләү эшләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 3 өлеше,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 23 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр күләмен раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эшләре турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче, 2 нче кушымталарда каралганча 6 964,68 сум күләмендә расларга.

2. 2021 елның 10 февралендә «Челнинские известия» газетасының 9 санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2021 елның 5 февралендәге 772 номерлы Башкарма комитет карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 18 февралендәге
750 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлегенә бәяләр
(якын туганнары, ире (хатыны) булган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1 800,00 |
| 3. Үлгән кешене (мәетне) зиратка илтү | 1 390,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 774,68 |
| Барлыгы | 6 964,68 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 18 февралендәге
750 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлегенә бәяләр
(якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне төрү | 300,00 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1 500,00 |
| 4. Үлгән кешене (мәетне) зиратка илтү | 1 390,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 774,68 |
| Барлыгы | 6 964,68 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева